КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 7 июль г.Казань № 647

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 27 июль, 659 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган коммерциягә карамаган оешмаларны тәэмин итә торган электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган коммерциягә карамаган оешмаларны тәэмин итә торган электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 27 июль, 659 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен, шулай

ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган коммерциягә карамаган оешмаларны тәэмин итә торган электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш (2022 елда салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча 300 мең сумнан артмаган, түләнмәгән бурыч булырга мөмкин);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2022 елда сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмаска тиеш.»;

10 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү сроклары, тәкъдимнәрне (заявкаларны) кабул итә башлау яки сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмаган тәкъдимнәрне (заявкаларны) кабул итү тәмамлану датасы (2022 елда тәкъдимнәрне (заявкаларны) кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин);»

16 пунктның сигезенче һәм тугызынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки, Министрлыкка бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеген булдырмауга китерә торган итеп киметкән очракта, яңа шартлар белән килешүгә ирешмәгәндә килешүне өзү турында шарт (2022 елда килешүнең яңа шартларын, шул исәптән кирәк булганда, башкарма хакимиятнең билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль органы килешү ягы булып тормаган очракта, әлеге орган вәкилләре катнашында килештерү тәртибе);

субсидия алучының, субсидияләр алучылар белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы.»;

23 һәм 24 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүне бәяләү Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән һәм фактта ирешелгән субсидия бирү нәтиҗәсен чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү нәтиҗәсе – агымдагы финанс елның 31 декабренә кадәр 32 бакча ширкәтендә Эшләрне тәмамлау.

2022 елда субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә килешүдә билгеләгән срокларда ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта, Министрлык, субсидия алучы белән килештереп, субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү срокларын (әмма иң күбе 24 айга) озайту өлешендә килешүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү мөмкинлеге булмаган очракта, Министрлык субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечен киметү турында карар кабул итәргә хокуклы.

24. Субсидия алучы, субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшыра.»;

25 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча аларның бозылуы ачыкланган һәм субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшырылмаган очракларда, тулы күләмдә;»;

27 һәм 28 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, ә дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу

буенча тиешле чара тәгәлләнү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.

26. Субсидия акчасын нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

2. Тәртипнең 6 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы егерме беренче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин